МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

28.10.2019

Казан

№ 556-пр

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне әлеге боерык белән расланган Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Түбәндәгеләрне көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 26.12.2017 № 3064-р карарын;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 26.12.2017 № 3064-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 19.12.2018 № 622-пр боерыгын.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
28.10.2019 № № 556-пр
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: – Россия Федерациясе Җир кодексы, федераль законнар, Татарстан Республикасы Җир кодексы һәм башка Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән, әлеге Регламентның 3нче кушымтасында күрсәтелгән гражданнар һәм юридик затлар.

Дәүләт хезмәтен алуга гариза бирүчеләр булып дәүләт хезмәтен алучылар яисә дәүләт хезмәтен алучының тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче вәкаләтле вәкилләре (алга таба – гариза бирүче) санала.

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр. Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43, 71 номерлы автобуслар белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – «Сукно бистәсе».

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: 221-40-39, 291-40-89.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган дәүләт хезмәте турында Министрлык эчендә урнаштырылган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайты) (http://mzio.tatarstan.ru.);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан «(http://uslugi.tatarstan.ru/)»;

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

5) дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкләргә мөрәҗәгать итеп.

1.3.5. Министрлыкның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы турында мәгълүмат, шулай ук, электрон почтасы, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкнең һәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкнең ераклаштырылган эш урынының урнашу урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан «Татарстан Республики дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмати системасындагы Министрлык рәсми сайтына һәм Татарстан Республики дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталына урнаштырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелгән (ПКМ 593) мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелгән мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2001, № 44, 4147 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Автоном учреждениеләр турында» 03 ноябрь 2006, № 174-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 45, 4626 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Кадастр эшчәнлеге турында» 24 июль 2007, № 221-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2007, № 31, 4017 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 27 июль 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010 ел, № 31, 4179 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 06.04.2011 № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, №15, 2036 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль закон («Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы» (www.pravo.gov.ru) 2015, 14 июль, бастырылган номеры 0001201507140007, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 07.05.2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, 2338 б.);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары, дәүләти бюджеттан тыш фонд органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында арадашлык турында» 27.09.2011 № 797 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба - № 797 карар) (РФ законнары җыелмасы, 03.10.2011, № 40, 5559 б.);

«Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә алу хокукын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 12.01.2015, № 1 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 1) («Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы» (www.pravo.gov.ru) 28.02.2015, басылу номеры 0001201502280007, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлегенә аренда килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында алдан килешү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү ысулларын һәм тәртибен раслау турында һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген, шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып гариза бирү, шулай ук аларның форматларына куелган таләпләр

турында» 14.01.2015, № 7 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 7) (Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 27.02.2015, урнаштырылу номеры 0001201502270011);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Республикасы, 1998, 15 август);

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 ел, № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 47-48, 0985 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 03.10.2007, № 37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 39, 1928 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе

турында» 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк, МФЦ) – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә җавап бирә һәм «бер тәрәзә» принцибында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, оештыруда вәкаләтле, дәүләти яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән оешма (шул ук вакытта автоном учреждение булып тора;

дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районнардагы (шәһәр округында) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис) (алга таба – МФЦның ерактагы эш урыны);

«бер тәрәзә» принцибы – гариза бирүченең дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән запрос белән мөрәҗәгатеннән соң аңа дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү принцибы, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар белән, муниципаль хезмәтләре күрсәтүче органнар белән арадашлыкны күпфункцияле үзәк норматив хокукый актлар һәм аралашлык турында килешүләр нигезендә гариза бирүченең катнашыннан башка үзе башкара;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) алар нигезләнгән документлардагы мәгълүмат белән туры килмәвенә китергән Министрлык җибәргән хата (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) - 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Мөрәҗәгатьнең киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү | РФ ҖК $39^{10}$ ст.;<br>ТР ҖК 21 ст.;<br>Нигезләмә 3.3.19 п. |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү турында карар һәм аның белән бергә җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану шартнамәсе проекты<br>Түләүсез файдалану өчен җир кишәрлеге бирүдән баш тарту турында карар | РФ ҖК $39^{10}$ ст.;<br>РФ ҖК $39^{14}$ ст.;<br>Нигезләмә 3.3.19 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы | Дәүләт хезмәте, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны тапшыру (җибәрү), Министрлыкта гариза регистрацияләнгән көннән башлап, 17 эш көне эчендә күрсәтелә. Гариза бирүченең җир кишәрлеген түләүсез файдалану шартнамәсен имзалау срогы дәүләт хезмәтен күрсәтү срогына керми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | РФ ҖК $39^{17}$ ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | караламаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны тапшыру гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документлар мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән элемтә ысулы белән (почта аша яки электрон адреска) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, шул исәптән, электрон формада һәм аны тапшыру тәртибе | Җир кишәрлеген түләүсез файдалану хокукы белән алу өчен, мөрәҗәгать (1 нче кушымта) белән бергә түбәндәге документлар тапшырыла:<br>1. Физик зат булган гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) шәхесен яисә физик яки юридик зат вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе.<br>2. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) вәкиле мөрәҗәгать итсә, физик яки юридик зат вәкиленең хокукын (вәкаләтләрен) раслаучы документ күчермәсе.<br>Гариза бирүчеләр өстәмә рәвештә 4нче кушымтада күрсәтелгән документларын тапшыралар.<br>Документларның күчермәсе нотариуста яисә документның оригиналын биргән органда (оешма, учреждение) расланган булмаса, оригиналлары да тәкъдим ителә һәм Министрлык белгече тарафыннан раслана. | Боерык № 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте алу өчен гариза формасын Министрлыкка мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьләр формасында түбәндәге ысуллар белән тапшырыла (юллана) ала:<br>шәхси (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән);<br>почта аша;<br>МФЦ аша.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, техник мөмкинлекләр булганда, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысасында алыналар:<br>1. Күчемсез милек объекты (соралган җир кишәрлеге) турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба - ЕГРНнан өземтә) өземтә, «Дәүләт теркәве, | Боерык №1;<br>ТР МК карары № 675 |

| | | |
|---|---|---|
| бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар саклангaн дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалыннан (алга таба – ТР ФКП)<br>2. Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар турында) ЕГРН өземтәсе (ТР ФКПтан).<br>3. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә (алга таба – ЕГРЮЛ) яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу бите, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР ФСХИ).<br>4. Коммерциячел булмаган оешма төзү турында карар күчермәсе (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан) – җир кишәрлеген аерым категория гражданнарны торак белән тәэмин итү өчен торак төзелеше максатларында Татарстан Республикасы законнарында каралган һәм Татарстан Республикасында төзелгән коммерциячел булмаган оешмага биргән очракта.<br>5. Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар турында) ЕГРН өземтәсе (бина, корылма төзелгән очракта кирәкми) – җир кишәрлеген дини яки хәйрия билгеләнешендәге | |

| | | |
|---|---|---|
| | биналар, корылмалар төзү өчен дини оешмага биргәндә.<br>Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үз ихтыяры белән тапшыра ала, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта электрон формада да.<br>Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен документлар кабул итеп алудан баш тартуга сәбәп булып тормый.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә килеп чыккан мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирүне, гамәлләр башкару таләп итү;<br>Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары карамагында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм (яисә) оешмаларда булган документлар һәм мәгълүмат бирелүне, шулай ук, аларны алу өчен түләү кертелүен раслаган докуемнтларны сорау. №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә | |

| | | |
|---|---|---|
| | каралган документлар искәрмә булып тора;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешендә 4 пунктында күрсәтелгән очраклар искәрмә булып тора. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Гаризаның РФ ЖК $39^{17}$ статьясының 1 пунктына туры килмәве, башка вәкаләтле органга тапшырылган булуы яисә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплектын тапшырмау.<br>2. Гаризада һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартылган, өстәп язылган һәм төзәтелгән урыннар булуы. | РФ ЖК $39^{17}$ ст.,<br>Боерык № 1 |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законда каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>Гариза бирүче тапшыра торган документларда дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар булу. | РФ ЖК $39^{16}$ ст.;<br>Боерык № 1 |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан оешмалар биргән документ (документлар) турында белешмә | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президенты Указы № 601, 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешманыд хезмәтен регистрацияләү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору урыннарына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазы һәм мәгълүмати стенд куелган бүлмәләрдә башкарыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| тутыру урынына, аларны тутыру үрнәкләре һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчне зарури документлар исемлеге урнаштырылган мәгълүмати стендларның урныштырылуына һәм әлеге хезмәт күрсәтелү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Инвалидларга каршылыксыз керә алу, шул исәптән каршылыксыз кереп чыгу мөмкинлеге белән тәэмин ителә, шул исәптән тиешле урынга килеп җитә алу максатында объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып, дәүләт хезмәтен дәүләти | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән, тулы күләмдә), башкарма хакимият органының гариза бирүче сайлаган теләсә кайсы территориаль бүлекчәсенә (экстерриториаль принцип) дәүләти һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләренә №210-ФЗ Федераль законның 15[1] статьясы нигезендә запрос биреп алып булу яки булмау мөмкинлеге | мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.<br>инвалидлар өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыру белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелергә комачаулаган башка барьерларны үтәргә булышу.<br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>Гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.<br>дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан | |

| | | |
|---|---|---|
| | артмый.<br>Дәүләт хезмәте МФЦ аша, МФЦның ерактагы эш урыны аша күрсәтелгәндә, консультацияне һәм документ кабул итү эшләрен МФЦ белгече, МФЦның ерактагы эш урыны белгечләре башкара.<br>Техник мөмкинлекләр булганда кирәкле документлар МФЦның мәгълүмати системасы аша электрон рәвештә (документларның скан-образы, (МФЦ ЭЦП имзасы белән) тапшырыла ала. Бу очракта кәгазьдәге документлар Министрлыкка «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы арасындагы килешүдә (алга таба – Килешү) күрсәтелгән вакытта юллана.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкка, МФЦга телдән (шәхсән үзе яки телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать итеп, Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша алырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплексны запрос буенча күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән, дәүләт хезмәтен экстерриториаль | Консультация алу өчен гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша Бүлеккә | |

| | | |
|---|---|---|
| принцип буенча күрсәтү үзенчәлекләрен истә тотып (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | мөрәҗәгать итә ала.<br>Дәүләт хезмәте электрон формада, шул исәптән, “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы” республика дәүләт мәгълүмати системасын файдаланып, күрсәтелми.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү турында карар проекты һәм җир кишәрелеген түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әзерләү;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү тәртибе, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып;

дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе булган документларда киткән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән үзе, телефоннан, һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән, дәүләт хезмәте алу өчен тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен МФЦ аша, МФЦның ерактагы эш урыны аша дәүләт хезмәтен алып булуы турында мәгълүмат бирә.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: консультация, шулай ук, күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен МФЦ аша, МФЦның ерактагы эш урыны аша дәүләт хезмәтен алып булуы турында мәгълүмат бирү.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән гаризасын Министрлыкка бирә, шул исәптән, МФЦ аша, МФЦның ерактагы эш урыны аша.

Гариза һәм нотариустан яки документның төп нөсхәсен биргән органнан (оешма, учреждение) раслатылган документларның күчермәсе почта аша юллана ала.

Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора.

3.3.2. Эш башкару бүлеге һәм контроль бүлеге белгече (алга таба – эш башкару бүлеге) түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны һәм документларны кабул итә;

гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече катнашында башкарыла;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта гаризаны һәм беркетелгән документларны теркәп, карау өчен Бүлеккә юллый;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта документларны теркәмичә генә, Бүлек белгече әзерләгән, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән аңлатма белән бергә, гариза бирүчегә кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган гариза һәм документлар; гариза бирүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.4.1. Бүлек белгече мөрәҗәгатьне һәм документларны эш башкару бүлегеннән алганнан соң «ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеге бирү турында гаризалар үтү битен» (2 нче кушымта) тутыра, ведомоствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада запрослар юллый:

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә бирүне сорап, яисә Шәхси эшмәкәрләрнед бердәм дәүләт реестрыннан белешмә бирүне сорап – ТР буенча ФСХИга;

күчемсез милек объекты (соралган җир кишәрлеге) турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестры (ЕГРН) белешмәсен сорап ФБУ «ТР буенча ФКП»га;

күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар һәм (яки) корылмалар турында) ЕГРН өземтәсе бирү турында ФБУ «ТР буенча ФКП»га;

коммерциячел булмаган оешма төзү турында карар күчермәсен бирү турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органына.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.4.2. Ведомоствоара арадашлык органнары белгечләре ведомоствоара электрон арадашлык системасы аша кергән 3.4.1 пунктта күрсәтелгән запрослар нигезендә законнарда билгеләнгән срокларда соралган белешмәләрне (документлар) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган белешмәләр (документлар), яисә, баш тарту турында министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.5. Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү турында карар проекты һәм җир кишәрелеген түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әзерләү

3.5.1. Әлеге Регламентның 3.3.2 пунктына туры китереп, ТР буенча ФСХИдан, ФБУ «ТР буенча ФКП», Татарстан Республикасы дәүләт

хакимиятенең вәкаләтле органыннан соратып алынган белешмәләр (документлар) килгәннән соң, Бүлек белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булуын тикшерә;

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү турында Министрлык карары проекты (алга таба – Министрлык карары проекты) һәм җир кишәрлекләрен түләүсез файдалану шартнамәсе проекты (алга таба - түләүсез файдалану шартнамәсе проекты), җир кишәрлекләрен түләүсез файдалану шартнамәсе проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә, баш тарту нигезен һәм ачыкланган кимчелекләрне бетерү тәкъдиме күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (алга таба - баш тарту турында карар) әзерли;

Министрлык карары проектын һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектын, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: әзерләнгән Министрлык карары проектын һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.2. Бүлек мөдире Министрлык карары проектын, түләүсез файдалану шартнамәсе проектын, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар проектын карап чыга, килештерә һәм килештерү өчен җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире белән килештерелгән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган Министрлык карары проекты һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.3. Идарә башлыгы Министрлык карары проектын һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектын, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.5.2, 3.5.3 пунктлар белән билгеләнгән процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, Бүлек белгеченә юлланган Министрлык карары проекты һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән Министрлык карары проектын һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектын, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хатны яисә баш тарту турында карар проектын хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, хокук идарәсенә юлланган Министрлык карары проекты һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.5. Хокук идарәсе белгече Министрлык карары проектына һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза уздыра һәм хокук идарәсе башлыгына килештерүгә Министрлык карары проектын һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын яисә, Министрлык карары проектына һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектына, баш тарту турында карар проектына кисәтүләр булган очракта, хокук идарәсе бәяләмәсе проектын имзаларга юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән Министрлык карары проекты, түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты яки Министрлык карары проектына һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектына, баш тарту турында карар проектына кисәтүләр булган очракта, хокук идарәсе бәяләмәсе проекты.

3.5.6. Хокук идарәсе башлыгы Министрлык карары проектын һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә яки хокук идарәсе бәяләмәсен имзалый һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән Министрлык карары проекты, түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты яки кисәтүләр булган очракта, хокук идарәсе бәяләмәсе проекты.

3.5.7. Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта кимчелекләрне бетерә һәм Министрлык карары проектын һәм (яки) түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын кабат хокук идарәсе башлыгына килештерергә юллый.

3.5.8. Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрнең бетерелү фактын тикшерә һәм Министрлык карары проектын түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.5.7 һәм 3.5.8 пунктларда билгеләнгән процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән Министрлык карары проекты, түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.9. Бүлек белгече хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән Министрлык карары проектын һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проектын, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хатны яисә баш тарту турында карар проектын имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы, хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән, министрның беренче урынбасарына юлланган Министрлык карары проекты һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат.

3.5.10. Министрның беренче урынбасары җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү турында Министрлык карарын (алга таба – Министрлык карары), шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хатны яисә, җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирүдән баш тарту турында карарны (алга таба – баш тарту турында карар) имзалый һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары имзалаган, теркәү өчен эш башкару бүлегенә юлланган Министрлык карары һәм түләүсез файдалану шартнамәсе проекты һәм шартнамәсе проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Эш башкару бүлеге белгече Министрлык карарын, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хатны, баш тарту турында карарны терки, гариза бирүчегә түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яки баш тарту

турындагы карарны бирү өчен билгеләнгән вакыт турында телефоннан хәбәр итә яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яки баш тарту турындагы карарны гариза бирүче күрсәткән почта адресына җибәрә. Министрлык карарын (баш тарту турында карарның күчермәсен) эш башкару бүлеге белгече Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: эш башкару бүлегендә теркәлгән Министрлык карары, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында карар; бүлеккә юлланган Министрлык карары (баш тарту турында карар күчермәсе).

3.6.2. Гариза бирүче түләүсез файдалану шартнамәсе проектын, баш тарту турындагы карарны алырга килгән очракта, эш башкару бүлегенең документларны бирүгә җаваплы белгече:

вәкилнең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен раслаучы документны тикшерә; вәкилнең вәкаләтләрен тикшерә (боерык, ышанычнамә һ.б.);

гариза бирүчегә түләүсез файдалану шартнамәсе проектын, баш тарту карарны бирә һәм исәп-хисап кенәгәсенә документлар тапшырылу турында язып куя.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә гариза бирүчегә бирелгән баш тарту карары.

3.6.3. Гариза бирүче алганнан соң утыз календарь көннән дә соңга калмыйча түләүсез файдалану шартнамәсен имзалый һәм министрлыкка китерә.

3.6.4. Министрның беренче урынбасары һәм гариза бирүче имзалаган түләүсез файдалану шартнамәсе Министрлыкның Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати хезмәттәшлек идарәсенең Татарстан Республикасының дәүләт милке реестры бүлегендә (алга таба – реестр бүлеге) теркәлә һәм гариза бирүчегә юллана.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче документларын китергәннән соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза бирүчегә юлланган түләүсез файдалану шартнамәсе.

3.7. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү тәртибе, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып

Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып та.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы техник хаталарны (алга таба – техник хата) төзәтү:

Гариза бирүченең түләүсез файдалану шартнамәсендә техник хата китү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаны төзәтелүенә нигез булып тора.

3.8.1. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында мөрәҗәгать (6 нчы кушымта);

түләүсез файдалану шартнамәсенең төп нөсхәсе;

техник хатаның булуын дәлилләгән документлар.

3.8.2. Түләүсез файдалану шартнамәсендә техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьне гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый.

3.8.3. Эш башкару бүлеге белгече кабул итеп ала һәм мөрәҗәгатьне, беркетелгән документлары белән бергә, теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура мөрәҗәгать һәм документлар бирелгән (кергән) көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карау өчен Бүлек белгеченә юлланган мөрәҗәгать.

3.8.4. Бүлек белгече документларны карап чыга һәм түләүсез файдалану шартнамәсенә үзгәрешләр кертү максатыннан (техник хаталарны төзәтү) Министрлык карарына һәм түләүсез файдалану шартнамәсенә үзгәрешләр кертү турында акт проекты әзерли һәм әлеге Регламентның 3.5.2, 3.5.3 – 3.5.10, 3.6.1, 3.6.2 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан хата җибәрелү турында мөрәҗәгать алган көннән соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган Министрлык карарына һәм түләүсез файдалану шартнамәсенә үзгәрешләр кертү турында акт проекты, түләүсез файдалану шартнамәсенә үзгәрешләр кертү проекты.

3.8.5. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документларны (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, Министрлык карарына үзгәрешләр кертү турында акт, үзгәрешләр кертелгән түләүсез файдалану шартнамәсен (техник хаталарны төзәтеп) Бүлек белгече Министрлыкта булган түләүсез файдалану шартнамәсе нөсхәсенә беркетә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны тикшерү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәвен тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

канцелярия эшләрен алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр үткәрү планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү буенча планнан тыш тикшерү карары түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларны бозу очраклары алдарак ачыкланып, аларның төзәтелүен тикшерү өчен;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының үз гамәлләре белән (гамәл кылмаулары белән) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулары турында гариза бирүчеләрнең зарланып мөрәҗәгать итү очрагында.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең, шулай ук, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата Министрлыкка шикаять белдерә ала.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

МФЦ хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять җитәкчегә бирелә, МФЦның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять МФЦны гамәлгә куючыга бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат, яки гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-

хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе бозылганда;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булып та, дәүләт хезмәтү күрсәтү туктатып торылса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр кабул иткәндә юклыгы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны яки мәгълүматны таләп итү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, МФЦ аша, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

МФЦның, МФЦ хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, МФЦ рәсми сайты аша, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, органның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәре, МФЦ, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, МФЦ, МФЦ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүмат;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, МФЦ, МФЦ хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре;

5.5. Шикаятькә анда бәян ителгәннәрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелә ала. Бу очракта шикаятькә беркетелгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять регистрацияләнгәннән соң унбиш көн эчендә карала, ә Министрлыкның, МФЦның гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Бу Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ясалган кимчелекләрне төзәтү өчен Министрлык, МФЦ кылачак гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче кылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелмәсә, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында дәлилле аңлатма бирелә, кабул ителгән краарга шикаять белдерү тәртибе бәян ителә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

## 6. Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә административ процедуралар (гамәлләр) башкару үзенчәлекләре

6.1. 6.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен МФЦга, МФЦның ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итергә хокуклы.

6.2. Дәүләт хезмәтен МФЦ һәм МФЦның ерактагы эш урыны аша күрсәтү МФЦның тиешле тәртиптә расланган регламенты һәм Килешү нигезендә башкарыла.

6.3. Документлар МФЦдан һәм МФЦның ерактагы эш урыныннан кергәч, әлеге Регламентның 3.3 - 3.6 пунктларында каралган процедуралар башкарыла.

6.4. Техник мөмкинлекләр булганда кирәкле документлар МФЦ мәгълүмат системасы аша электрон рәвештә (ЭЦП МФЦ белән имзаланган скан-образлар) тапшырыла. Бу очракта кәгазь документлар Министрлыкка Килешүдә күрсәтелгән вакытта юллана.

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән Административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

Җир кишәрлеген түләүсез файдалану хокукында бирү турында гариза

______________________________________________________________________________

(юридик затның атамасы, физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булса))

______________________________________________________________________________,

(гариза бирүченең интересларын яклаган вәкил - физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, юридик затларның вәкиле өчен – өстәмә рәвештә вәкилнең вазыйфасы)

________________________________________________________ нигезендә эш итеп

(вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ исеме)

__________________________________________________________________ өчен

(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)

________________________________________________________ хокукында булган

(хокукның исеме)

Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{10}$ ст., 2 п. туры китереп, түләүсез файдалану хокукында

____________________________________________ җир кишәрелеген бирүне үтенә.

(җир кишәрелегенең урыны, гомуми мәйданы күрсәтелә)

| N пп | Реквизитның атамасы | Реквизит эчтәлеге (мәгънәсе) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | **гражданин өчен:**<br>- гариза бирүченең яшәү урыны;<br>- гаризаның шәхесен таныклаган документ турында белешмә:<br>- документ төре;<br>- дата;<br>- серия;<br>- номер;<br>- исеме;<br>- документны биргән орган): | ____________________<br><br><br>____________________<br>____________________<br>____________________<br>____________________<br>____________________<br>____________________ |
| 2 | **юридик зат өчен:**<br>- гариза бирүченең урнашкан урыны;<br><br>- юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затның дәүләт теркәве | ____________________<br><br>____________________ |

| | | |
|---|---|---|
| | турында язманың дәүләт теркәве номеры;<br>- салым түләүченең идентификацион номеры, гариза бирүченең чит ил юридик заты булуы искәрмә булып тора: | ___ |
| 3 | Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 ст.ның 2 п.ында каралганнар арасында җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча түләүсез файдалануга бирү нигезе: | ___<br>___<br>___ |
| 4 | Җир кишәрлеге дәүләт ихтыяҗы белән тартып алынган җир кишәрлегенә алмашка бирелгән очракта, җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗы буенча алу турында карар рекквизитлары:<br>- документ төре;<br>- дата;<br>- номер;<br>- исеме;<br>- карар кабул иткән орган: | ___<br>___<br>___<br>___<br>___ |
| 5 | Җир кишәрлеген әлеге документта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелә икән, территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары:<br>- документ төре;<br>- дата;<br>- номер;<br>- исеме;<br>- карар кабул иткән орган: | ___<br>___<br>___<br>___<br>___ |
| 6 | Әлеге документ нигезендә соралган җир кишәрлеге ясалган яки чикләре төгәлләштерелгән икән, җир кишәрлеген бирү турныда алдан килештерү турында карар реквизитлары:<br>- документ төре;<br>- дата;<br>- номер;<br>- исеме;<br>- карар кабул иткән орган: | ___<br>___<br>___<br>___<br>___ |
| 7 | Гариза бирүче белән элемтәгә керү өчен почта адресы: | |

| | | |
|---|---|---|
| 8 | Гариза бирүче белән элемтәгә керү өчен электрон почта адресы: | |

«Персональ мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (_______№_________________________ышанычнамә буенча вәкил

_______________________________________/_______________________/

(вәкилнең фамилия, имя, этисе исеме, имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"__________ 20__ г.

_______/__________________/гаризаны алган белгечнең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Җир кишәрлеген түләүсез файдалану
хокукында бирү турында гаризага кушымта

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре министрлыгына

## __________________________________ кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез милек объектларының исемлеге

| Күчемсез милек объект(лар)ының исеме | Күчемсез милек объект(лар)ының кадастр (инвентарь) номеры | Күчемсез милек объект(лар)ының адрес ориентиры |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Җир кишәрлегендә ______________________________ адресы белән урнашкан _____________________ га мәйдан биләп торган бөтен биналар һәм корылмалар _______________________________________________________________ _________________

Хәзерге вакытта______________________________________________ милке булып санала.
(оешманың исеме),
Өченче затларның хокуклары һәм претензияләре юк.

Җир кишәрелегендә урнашкан, башка юридик (физик) затларның милке булган (хуҗалык алып бару, оператив идарә) күчемсез милек объектлары:

бар (хокук ияләрен күрсәтергә) _________________________________

юк

Җир кишәрелегендә урнашкан мобилизация билгеләнешендәге һәм гражданнар оборонасы объектлары:

бар (санап үтәргә): ______________________________________________

юк

Җитәкче _____________________________ фамилия, инициаллар
(имза)

М.П. (мөһер булганда)

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән Административ регламентына 2 нче кушымта

# ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында түләүсез файдалану хокукында җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгатьләр үтү бите

Гариза бирүче ________________________________________________

Регистрация (теркәү) номеры _________________________

| N п/п | Министрлыкның структур бүлекчәсе | Алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Эш башкару һәм контроль бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 8. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 9. | Эш башкару һәм контроль бүлеге (документларны рәсмиләштерү һәм теркәү) | | | | |

Татарстан Республикасы милкендә булган
җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән
Административ регламентына
3 нче кушымта

## Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләре түләүсез файдалануга бирелә алган гражданнар һәм юридик затлар исемлеге

1) дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары;

2) дәүләти һәм муниципаль учреждениеләр (бюджет, казна, автоном);

3) казна предприятиеләре;

4) Россия Федерациясенең үз вәкаләтләрен башкаруны туктаткан президентларының тарихи мирас үзәкләре;

5) ун елга кадәр срок белән, дини яисә хәйрия биналарын, корылмаларын урнаштыру өчен дини оешмалар;

6) әгәр ул җирдә түләүсез файдалану хокукында аларга караган биналар, корылмалар урнашкан булса, дини оешмалар – күрсәтелгән бинага, корылмага хокук срогы беткәнчегә кадәр;

7) "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабына объектлар төзелеше яисә реконструкция буенча гражданлык-хокук шартнамәсе төзелгән затлар;

8) Татарстан Республикасы законнары белән белгеләнгән шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмчел хуҗалык шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыклары эшчәнлеге өчен муниципаль берәмлекләрдә җир кишәрлеге бирелгән гражданнар, алты елдан да артмаган срокка;

9) Татарстан Республикасы законнары белән белгеләнгән шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмчел хуҗалык шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен муниципаль берәмлекләрдә җир кишәрлеге бирелгән һәм әлеге муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән белгечлекләр буенча эшләүче гражданнар, алты елдан да артмаган срокка;

10) хезмәт торагы булган йорт урнашкан җир кишәрлеген алу өчен хезмәт торагы итеп йорт бирелгән гражданнар, әлеге торак йорт белән файдалану срогында;

11) яшелчәчелек яисә бакчачылык өчен гражданнар төзегән коммерциячел булмаган оешмалар - биш елдан да артык булмаган срокка;

12) торак төзелеше максатыннан гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар – федераль законнарда каралган очракларда һәм срокларда;

13) федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указы, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән аерым категория гражданнарын торак белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы законнарында каралган һәм Татарстан Республикасында төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар – әлеге торакларны төзү максатыннан күрсәтелгән төзелеш вакытында;

14) Җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗы өчен алу сәбәпле, Татарстан Республикасы милкендә булган бу җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукы бетерелгән затлар – алынган җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукына бәйле рәвештә законнар белән билгеләнгән билгеләнгән срокларда.

Татарстан Республикасы милкендә
булган җир кишәрлекләрен түләүсез
файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең теркәлгән Административ
регламентына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчеләр тарафыннан өстәмә тапшырыла торган документлар исемлеге

1. Дини оешмалар - әгәр ул җирдә түләүсез файдалану хокукында аларга караган биналар, корылмалар урнашкан булса, срогы - әлеге биналарга, корылмаларга хокук беткәнчегә кадәр:

әлеге биналарга, корылмаларга хокук ЕГРНда теркәлмәгән булса, биналар, корылмалар белән түләүсез файдаалану шартнамәсе;

әлеге җир кишәрлегенә хокук ЕГРНда теркәлмәгән булса (җир кишәрлегенә тиешле хокуклар булган очракта), гариза бирүченең соралган җир кишәрлегенә хокукын такныклаучы (билгеләүче) документлар;

гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) соралган җир кишәрлегендә урнашкан, гариза бирүченең хокуклары булган барлык биналарның, коралмаларның кадастр (шартлы, инвентарьлы) номерлары һәм адрес ориентирлары белән бирелгән исемлеге күрсәтелгән хәбәре.

2. "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, тулысынча Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы хисабына объектлар төзелеше яисә реконструкция буенча гражданлык-хокук шартнамәсе төзелгән затлар – шартнамә үтәлү срогына;

тулысынча Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы яисә җирле бюджет акчалары хисабына объектлар төзелеше яисә реконструкция буенча гражданлык-хокук шартнамәләре.

3. Җир кишәрлеген Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән муниципаль берәмлекләрдә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмчел хуҗалык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге максатларында алган гражданнар – алты елдан да артмаган срокка:

Фермер хуҗалыгы берничә граждан тарафыннан төзелгән булса, крестьян (фермер) хуҗалыгы төзелү турында килешү (эшчәнлеге крестьян (фермер) хуҗалыгын алып бару булса).

4. Җир кишәрлеген Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән муниципаль берәмлекләрдә индивидуаль торак төзелеше, шәхси

ярдәмчел хуҗалык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге максатларында алган һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән белгечлекләр буенча төп эш урыны әлеге муниципаль берәмлекләрдә булган гражданнар – алты елдан да артмаган срокка:

эшкә алу турында боерык, хезмәт кенәгәсеннән өземтә яисә хезмәт шартнамәсе (контракт).

5. Җир кишәрлегендә гражданнарга бирелгән торак йорт рәвешендәге хезмәт торагы урнашкан булса – әлеге торак белән файдалану срогында:

хезмәт торагына найм шартнамәсе.

6. Торак төзелеше максатыннан гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар – федераль законнарда каралган очракларда һәм срокларда:

коммерциячел булмаган оешма төзү карары.

7. Җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗы өчен алу сәбәпле, Татарстан Республикасы милкендә булган бу җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукы бетерелгән затлар – алынган җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукына бәйле рәвештә билгеләнгән срокларда:

җир кишәрлеген дәүләти яисә муниципаль ихтыяҗ өчен алу турында килешү яки җир кишәрлеген дәүләти яисә муниципаль ихтыяҗ өчен алуга нигез булган суд карары.

Татарстан Республикасы милкендә
булган җир кишәрлекләрен түләүсез
файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең теркәлгән Административ
регламентына 5 нче кушымта

**Җир кишәрлеге бирүдән баш тарту өчен нигезләр:**

1) 1) җир кишәрлеге бирү турында җир законнары буенча сатулашулар үткәрмичә бирү алу хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итә;

2) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас ителгән биләмәләр яки аренда хокукында бирелгән; җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокуклары булган кеше мөрәҗәгать итүе яисә җир кишәрлеге бирү турында гаризаның РФ ҖКның $39^{10}$ статьясының 2 пункты 10 подпунктына туры китереп бирелгән булуы чыгарма булып тора.

3) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге яшелчәчелек яки бакчачылык коммерциячел булмаган ширкәтенә бирелгән җирне бүлеп ясалган; әлеге коммерциячел булмаган ширкәтнең әгъзасы (әлеге җир кишәрлеге бакча яки яшелчә җире булса) яисә, гражданнар үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек яки бакчачалык эше алып барган территория чигендәге җир кишәрлекләренең милек иясе (җир кишәрлеге гомуми файдаланыла торган милеккә кергән очракта) мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

4) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге хосусый торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен коммерциячел булмаган оешмага бирелгән, җир кишәрлеге әлеге оешманың гомуми файдалану кишәрлеге булып торган һәм әлеге оешма әгъзасы яисә әлеге оешма мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

5) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган биналар, корылмалар, төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан; корылма (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылма) җир кишәрлегендә сервитут, гаммәви сервитут шартларында, яки РФ ҖКның $39^{36}$ статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан очраклар яисә җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән әлеге бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе мөрәҗәгать иткән очраклар, шулай ук, җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән һәм әлеге җир кишәрлегендә үзбелдекле төзелгән бинаны, корылманы, төзелеп бетмәгән объектны сүтү турында, яки үзбелдекле төзелешне сүтү яисә билгеләнгән срокларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында кабул ителгән карар һәм Россия Федерациясенең Шәһәр

төзелеше кодексының 11 55[32] статьясының 11 өлеше үтәлмәгән очраклар чыгарма булып тора;

6) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләти яки муниципаль милек булган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан; корылма (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылма) җир кишәрлегендә сервитут шартларында урнашкан очраклар яисә җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән әлеге бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектка хокукы булган зат мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

7) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган булса яисә әйләнеше чикләнгән булып, җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокук буенча бирергә ярамый;

8) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт ихтыяҗларына резервка куелган булып, гариза бирүче җир кишәрлеген милек итеп даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә җир кишәрлеген арендага җир кишәрлеген резервка кую турында карар гамәлдә булганнан озаграк вакытка түләүсез файдалануга бирү турында мөрәҗәгать итсә; җир кишәрлеген резервка кую максатыннан бирү чыгарма булып тора;

9) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территориянең үсеше турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан; җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән шушы җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе яки әлеге җир кишәрлегенә хокукы булган зат  мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

10) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территориянең үсеше турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган; җир кишәрлеге федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыруга билгеләнгән булып, җир кишәрлеген бирү турында әлеге объектларны төзергә вәкаләтле затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

11) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган һәм территориянең планы буенча расланган документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыруга

билгеләнгән; җир кишәрлеген арендага алу турында гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән һәм әлеге объектларны төзү йөкләмәсе булган затның мөрәҗәгать итүе чыгарма булып тора;

12) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында белдерү РФ ҖКның $39^{11}$ статьясының 19 пунктына туры китереп урнаштырылган;

13) мөрәҗәгатьтә күрсәтелеп соралган җир кишәрлеге буенча РФ ҖКның $39^{11}$ статьясының 4 пункты 6 подпунктында каралганча аны сату өчен яисә әлеге җир кишәрлеге РФ ҖКның $39^{11}$ статьясының 4 пункты 4 подпунктын туры китереп ясалган булса аны арендага алу өчен шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү турында белдерү кергән һәм вәкаләтле орган РФ ҖКның $39^{11}$ статьясының 8 пункты нигезендә аны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итмәгән;

14) мөрәҗәгатьтә күрсәтелеп соралган җир кишәрлеге буенча Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{18}$ статьясының 1 пункты 1 подпунктына туры китереп, җир кишәрлеген индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмчел хуҗалык, бакчачылык, дача хуҗалыгы яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге максатларында бирү турында белдерү урнаштырылган;

15) җир кишәрлеген файдалануга рөхсәт бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеген файдалану максатларына туры килми; территориянең планлаштыруның расланган проектына туры китереп линияле объект урнаштыру очраклары чыгарма булып тора;

16) соралган җир кишәрлеге территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чигендә урнашкан, җир кишәрлекләрен файдалануның билгеләнгән чикләүләре җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән файдалану максатларына туры килми;

17) җир кишәрлеген мөрәҗәгать ителгән хокук төре буенча бирү каралмаган;

18) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;

19) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге җирләрнең билгеле категорияләренә кертелмәгән;

20) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата аны бирү буенча алдан килештерелгән һәм ул гамәлдән чыкмаган, мөрәҗәгать белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка кеше чыккан;

21) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максатлары әлеге җир алынган максатларга

туры килми; әлеге җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йорт тузган һәм сүтелергә яисә төзекләндерелергә тиеш дип танылу сәбәпле, җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган булу чыгарма булып тора;

22) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль законга туры китереп анықланырга тиеш;

23) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасына, территорияләрне ызанлау проектына туры китереп ясалган булса да, аларда күрсәтелгәннән ун процентtan да күбрәккә артып китә.

Татарстан Республикасы милкендә
булган җир кишәрлекләрен түләүсез
файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең теркәлгән Административ
регламентына 6 нчы кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

Техник хатаны төзәтү турында гариза

_______________________________________________________________________________
(юридик зат атамасы, физик затның, шәхси эшмәкәр Ф.И.АИ (соңгысы – булса))
______________________________________________________________________________,
(Ф.И.АИ (соңгысы – булса), вәкилнең вазыйфасы)

________________________________________________________ нигезендә эш итүче
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ)

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «____»_________ 20______ел. №________ карарына тиешле үзгәртүләрне кертүне үтенә

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «____» _________ 20______г. №________карарында («____» _________ 20______г. №________җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү шартнамәсендә)
_______________________________________________________________ дип язылган

Дөрес белешмә:________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Гариза бирүче (гариза бирүчеләр) турында белешмә:

| | |
|---|---|
| Юридик зат өчен реквизитлар *(ОГРН, ИНН, адрес (урнашу урыны)*<br>Физик зат өчен (юридик затның вәкиле) паспорт мәгълүматы *(серия, номер, кем һәм кайчан биргән, подразделение коды, теркәлү адресы),*<br>Яшәү адресы (теркәлү адресы белән туры килмәгән очракта), ИНН | |
| Контакт өчен телефон, почта | |

| | |
|---|---|
| адресы һәм (яисә) электрон почта адресы | |
| Җир кишәрлеге турында белешмә | |
| Кадастр номеры | |
| Җир кишәрлегенең урнашкан урыны: | |

«Персональ мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (_______№__________________________ышанычнамә буенча вәкил _________________________________________/________________________/
(вәкилнең фамилия, имя, әтисе исеме, имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"__________ 20__ г.
______/__________________/гаризаны алган белгечнең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасы милкендә булган
җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән
административ регламентына
кушымта (белешмәлек)

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83<br>221-40-79 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты,
Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе<br>Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru |